ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 104-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 104-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 393-VII ДС

104-7 номерлы проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 - 8, № 9 (II өлеш); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 ( өлеш I), № 17 (өлеш I), № 52 (өлеш I), № 55 ( өлеш I), № 94 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (өлеш I), № 54 (өлеш I), № 78 (өлеш I); 2019, № 2 (өлеш I), № 19 (өлеш I), № 49 (өлеш I); 2020, № 4 (өлеш I), № 37 (өлеш I), № 57 (өлеш I), № 87 (өлеш I); 2021, № 1 (өлеш I), № 57 (өлеш I); 2022, № 3 (өлеш I), № 24 (өлеш I); 2023, № 11 (өлеш I), № 27 (өлеш I), № 73 (өлеш I), № 81 (өлеш I), № 92 (өлеш I); 2024, № 18 (өлеш I), № 34 (өлеш I), № 47 (өлеш I), № 79 (өлеш I), № 93 (өлеш I) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге үрнәк квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш; югары белем яисә урта һөнәри белем булу – авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы булу;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы булу.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның «Малая Родина – сила России» икенче Бөтенроссия муниципаль форумы кысаларында муниципаль берәмлекләр башлыклары белән очрашу йомгаклары буенча 2025 елның 21 апрелендәге пр-1223 номерлы йөкләмәләре исемлегенең 3 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә эшләнде. Аның нигезендә Россия Федерациясе субъектларына махсус хәрби операциядә катнашучыларга муниципаль хезмәткә керү өчен шартлар тудырыру, шул исәптән муниципаль хезмәт яисә белгечлек буенча эш стажына квалификация таләпләрен, әзерлек юнәлешенә, шулай ук белем дәрәҗәсенә таләпләрне уңайлаштыру бурычы йөкләнә.

Республикада муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясында билгеләнгән.

Югарыда күрсәтелгән йөкләмәне үтәү максатларында закон проектында авыл җирлекләрендә вазыйфаларның югары һәм баш төркемнәре өчен белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләрен киметү, шулай ук муниципаль хезмәт яисә белгечлек буенча эш стажына карата кодекста билгеләнгән таләпләрне киметү карала.

Бүгенге көндә республикада «Батырлар. Герои Татарстана» кадрлар программасы эшли, ул махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына ярдәм итүгә, аларның дәүләт һәм муниципаль идарә системасында карьера үсеше өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Проектта республиканың 1 600дән артык кешесе катнашты. Финалга махсус хәрби операциядә катнашкан 45 кеше сайлап алынды, аларның 11е югары белемле түгел.

Законны кабул итү махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм махсус хәрби операция ветераннарының потенциалын муниципаль идарә системасында файдаланырга мөмкинлек бирәчәк.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.